РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 21 мае № 22

Түбән Кама шәһәр Советының хезмәт өчен түләүгә кагылышлы кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылый торган «Бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 14 апрелендәге 226 номерлы һәм 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктта «13 990» санын «15 389» санына алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

1.3. 14 нче кушымтада «кырык бер процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 22 нче кушымтаның 6 пунктында «кырык бер процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

2. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама шәһәре бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.1. 1 нче пунктның дүртенче абзацында «13 990» санын «15 389» санына алмаштырырга;

2.2. 3 нче пунктның 3 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

2.3. 8 нче пунктның 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

3. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә юнәлтә.

4. Түбән Кама шәһәре Уставы белән билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеше буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын башкаручы, Мэр урынбасары — М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр
Советының 2025 елның
21 маендагы 22 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Түбән Кама шәһәр
Советының 2021 елның
1 сентябрендәге 39
номерлы карарына
1 нче кушымта

Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны
акчалата бүләкләү күләме

| №<br>п/п | Хезмәт хакын түләү буенча төркем<br>(муниципаль берәмлек халкы санына карап) | 4 нче төркем |
|---|---|---|
| | | 100 дән 250 меңгә кадәр кеше |
| 1 | Түбән Кама шәһәре Мэры | 42 778 |
| 2 | Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары | 38 498 |
| 3 | Депутат | 20 733 |
| 4 | Җирле үзидарәнең сайлану органнары әгъзасы | 17 621 |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

М.В. Камелина